*“Татарстан  Республикасы Нурлат шәһәре*

*13 нче номерлы “Талым” балалар бакчасы” мәктәпкәчә*

*белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе*

Кабул иттелде

уздырма җыелышта

” 29 “ август 2018

Раслыйм______________

МББМУ «Талым» балалар бакчасы

мөдире Р.В.Абдуллина

Боерык №178 “29” август 2018 ел

# “Сабыйга” түгәрәгенең эш бүленеше

***Әзерләде татар теле тәрбиячесе:***

***Бикташева Ландыш Сәлихҗан кызы***

**Аңлатма язуы**

**Кереш.**

Туган тел-рухи байлыгыбыз сандыгына ачкыч. Халкыбызның гасырлар буе яшәп килгән, буыннан-буынга тапшырылган тормыш тәҗрибәсен, гореф-гадәтләрен, әхлак кануннарын, йола- бәйрәмнәрен, рухи байлыгыбызны тирәнтен аңлау һәм үзләштерү туган телдән башка мөмкин түгел. Ана телендә тәрбияләнгән бала гына аның әхлак кануннарын кабул итеп, милләтенә, аның теленә, гореф-гадәтләренә ихтирамлы була ала.

Гаилә һәм мәктәп баланы китапка һәм язма әдәбиятка алып керәләр. Бу ике арада халык авыз иҗаты күпер хезмәтен үти, язучылар, композиторлар өчен һәрвакыт илһам чыганагы булып тора . Моның шулай икәненә укучылар да инанырга тиеш. Ә бүгенге катлаулы заманда укучыларны иҗат дөньясына алып керү укытучыдан гаҗәеп дәрәҗәдә тырышлык, түземлелек, осталык сорый. Иҗат эшенең олы бәхет икәнлегенә укучыларны төшендерү – тел-әдәбият укытучыларының изге бурычы.

Әдәбият-иҗат түгәрәге – сәләтле балаларны барлау, аларның иҗади фикер йөртүен үстерү буенча дәрестән тыш эшләрнең иң нәтиҗәле формаларыннан берсе.

**Оештыру юнәлешендәге максат –** мәктәп кысаларында әдәбиятны традицион нигездә өйрәнүче укучыларны фәнни фикерләүгә корылган, кызыклы һәм файдалы концепция белән таныштыру.

**Түгәрәкнең эчтәлеге ягыннан максаты** – татар халкының әдәби мирасын бербөтен итеп системада, гадәтидән катлаулыга принцибы нигезендә, закончалыкларга таянып өйрәнү һәм милләтпәрвәр укучы тәрбияләү.

Әдәбият – сәнгатьнең иҗади фикерләүне үстерүгә корылган шактый катлаулы төре. Шуңа да “Татар халык авыз иҗаты”н өйрәнү процессында формалашкан махсус белемнән күнекмәгә кадәр үтелгән юл түбәндәге **бурычларны** хәл итүне таләп итә:

- укучыга фольклор турында системалы мәгълүмат бирергә, шул нигездә махсус белем һәм күнекмәләр формалаштырырга;
- логик закончалыкларга таянып, анализ барышында, баланы уйларга өйрәтергә, аның фикерләвен үстерергә;
- сәнгатьчә фикерләү алымнарын үзләштереп, укучыны иҗади эшчәнлеккә алып чыгарга;
- бәйләнешле сөйләмнең телдән һәм язма формаларын үстереп, мөстәкыйль фикерләргә сәләтле булган һәм фикерен ачык әйтә белүче шәхес тәрбияләргә;
- укучыга үзе теләгән әсәрләр белән эшләргә, эзләнергә, иҗат итәргә юл ачарга;

- мәстәкыйль эзләнүгә этәргеч ясарга;
- укучыларда халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре, динен өйрәнү аркылы туган телгә һәм халкыбызга мәхәббәт һәм ихтирам хисләре тәрбияләргә.

**Түгәрәк программасының максатлары:**

-фольклор хакында фәнни күзаллау тудыру. Аны халыкның коллектив иҗаты буларак күрсәтү, аның татар әдәбиятын формалаштыру һәм милли үзенчәлекләрен булдырудагы ролен күрсәтү ;

-халык авыз иҗаты жанрлары, аларның үзенчәлекләре, эчтәлеге һәм формасы, поэтикасы белән таныштыру;

-алган белемнәрне гамәлдә кулланырга, халык иҗаты берәмлекләрен җыярга, системалаштырырга, анализларга өйрәтү;

-халыкның тарихы, мәдәнияте, тормыш-көнкүреше, яшәү рәвеше белән кызыксыну уяту;

-кешеләр белән аралашырга, алар белән әңгәмә корырга өйрәтү.

Балаларга ия булырга тиешле **белем һәм күнекмәләр:**

- сәнгать телен аңлау өчен, кулланылган әдәби алымнарны үзләштерү;
- әсәргә бәя бирү өчен, логик гамәлләрне өйрәнү (анализ, синтез, гомумиләштерү, нәтиҗә һ.б.);
- халык авыз иҗаты берәмлекләрен җыярга, системалаштырырга, анализларга өйрәнү.

Түгәрәк утырышлары балаларның танып-белү һәм иҗади эшчәнлеген оештыруга корылган.Балалар халык авыз иҗаты турында дәресләрдә үзләштергән белемнәрен тирәнәйтәләр, фольклорны җыярга, тупларга өйрәнәләр; төрле яшьтәге, төрле характердагы, яшәү дәрәҗәләре төрле булган кешеләр белән аралашу күнекмәләрен ныгыталар; халыкның җанлы сөйләм теле белән якыннан танышалар.
Планда төрле очрашулар, әдәби кичәләр үткәрү дә каралган.
Бәйләнешле сөйләм үстерү, сәнгатьлелек, культуралы сөйләм кебек проблемалы мәсьәләләр дә урын алган.
Түгәрәк утырышлары махсус расписание нигезендә үткәрелә.

**Түгәрәкне оештыруның актуальлеге**

Сөйләм үстерү шөгыйлҗләрендә төрле типтагы иҗади эшләр башкарыла. Әмма халык авыз иҗаты белән кызыксынучы балалар өчен фольклор серләренең тәмен, серен, нечкәлекләрен җентекләп өйрәнү, киң мәйдан ачу түгәрәк утырышларыннан башка мөмкин түгел, минемчә. Түгәрәк утырышларында хезмәт җимешләрен бергәләп редакцияләү, матбугатка тәкъдим итү кебек эшләргә дә мөмкинлекләр зур.

**Үз белемеңне күтәрү**

Фән-мәдәният яңалыклары белән танышып бару.

Танылган кешеләр белән аралашу, очрашулар оештыру.

Вакытлы матбугат белән даими танышу.

Театр, концерт, кичәләргә йөрү.

Семинар-конференцияләрдә катнашу, чыгышлар ясау.

Тәҗрибә уртаклашу. Башка түгәрәкләр эше белән танышу, анализлау.

**Ата-аналар белән эш**

Түгәрәккә йөрүче балаларның ата-аналары белән элемтәдә тору.

Ата-аналарны очрашуларга чакыру.

Ата-аналар белән берлектә төбәк халык-авыз иҗаты әсәрләрен җыюны оештыру.

**Сәламәтлекне саклау**

Балаларның түгәрәккә үз теләкләре белән йөрүләренә ирешү.

Утырышларны ялыктырмаслык итеп үткәрү.

Ял минутлары уздыру.

Куркынычсызлык буенча инструктаж үткәрү.

**Эчтәлегенең төзелеше**

План 4 бүлектән тора һәм алар темаларга бүленгән.

I бүлек. Кереш. Татар халык авыз иҗаты.

II бүлек. Халык авыз иҗаты әсәрләренә анализ.

III бүлек. Төбәк халык-авыз иҗаты әсәрләрен җыю.

IV бүлек. Эшләрне анализлау, редакцияләү, презентацияләр ясау.

| **Сәг.саны** | **Эшчәнлек төре** |
|---|---|
| 1 | **Кереш. Татар халык авыз иҗаты.** |
| 2 | **Мәкальләр, әйтемнәр.**<br>Табышмаклар.<br>Уеннар.<br>Санамышлар.<br>Әкиятләр.<br>Тизәйткечләр. Шарадалар.<br>Йолалар. Бәйрәмнәр. |
| | **Халык авыз иҗаты әсәрләренә анализ:**<br><br>-мәкальләр, әйтемнәр, сынамышлар;<br>-табышмаклар;<br>-җырлар, бәетләр, такмаклар;<br>-әкиятләр, дастаннар;<br>-мәзәкләр, такмазалар;<br>-уеннар, санамышлар;<br>-тизәйткечләр, шарадалар;<br>-йолалар, бәйрәмнәр |
| 3 | Төбәк халык-авыз иҗаты әсәрләрен җыю |
| 4 | Эшләрне анализлау, редакцияләү, презентацияләр ясау. |

**Программаның эчтәлеге**

Тема 1. Татар халык авыз иҗаты, аның төрләре. Балалар фольклорының халык авыз иҗаты әсәрләренә нигезләнеп төзелүе.

Н. Исәнбәтнең китабы, өстәмә әдәбият, методик ярдәмлекләр.

Тема 2. Халык авыз иҗаты әсәрләре, сәнгать теле, образ, предмет, аның сыйфатлары:

- фикерләү алымнары буларак анализ (таркату), синтез, гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару;
- өлешләргә анализ, алар арасында бәйләнеш, әсәр төзелеше;
- метафора, сүз, күренешнең, предметның метафора вазыйфасын үтәве, метафора ярдәмендә эчтәлек табу;
- кабатлау алымы;
- образның мәгънә тудыруы, символ (үз эчтәлеген югалтып, башка эчтәлек белән килү);
- әсәрнең исеме, аның метафора һәм символ ролен үтәве, күпмәгънәлелеге һ.б.

Тема 3. Халык авыз иҗаты әсәренә анализ ясау үзенчәлекләре; тормыш күренешләренә, вакыйгаларына бәя бирүче жанрлар - әйтемнәр, мәкальләр, табышмаклар, җырлар; аларның кешеләрне тормыш шартларына ярашырга өйрәтүе, тормышның үзен үзгәртүче жанрлар - мәзәкләр, әкиятләр, дастаннар:

- әйтемнәр һәм мәкальләрнең үзенчәлекләре, охшаш һәм аермалы яклары;
- табышмаклар; каршы якларны берләштерү һәм бербөтенне каршы якларга бүлү гамәлләре нигезендә табышмаклар ясалу;
- җырлар һәм бәетләр; аларның төзелешләре, хискә нигезләнүе, хиснең өч өлешкә бүленүе (сәбәбе, дәрәҗәсе, юануы);
- мәзәкләр һәм әкиятләр жанрларының төп үзенчәлекләрен ачыклау.
- Йолалар, бәйрәмнәр , аларга хас үзенчәлекләрне билгеләү.

Тема 4. Фольклор җыю эшенә әзерлек мәсьәләләре.

-эшлисе авыл, район, төбәкнең тарихы, сөйләш үзенчәлекләре, кайсы диалектка караган булуы;

- фольклор үрнәкләрен теркәү таләпләре (теркәүне төгәл башкару; теге яисә бу диалект сөйләшенә хас булган төп үзенчәлекләрне саклап теркәү; текстны дөрес өлешләргә бүлеп язу; текстка пөхтә итеп башкарылган төгәл паспорт әзерләү; әсәр турында системалы һәм объктив белешмә туплау).

Тема 5. Халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю.

Тема 6. Эшләрне анализлау, редакцияләү, презентацияләр ясау. Яклап чыгышлар ясау.

**Әдәбият**

Н. Исәнбәт. Балалар фольклоры. Казан, 1984 ел.
“Фән һәм мәктәп” журналлары, №2, №5-6, 2006 ел.
“Мәгариф” журналлары, №10, 2000; №1, 2001 ел.
Н. Исәнбәт. Татар халык мәкальләре. Яр Чаллы, 2000 ел.
И. Н. Надиров. Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. Казан, 1988 ел.
Я. Г. Абдуллин. Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры. Казан, 1993 ел.
Г. Гыйльманов. Идегәй. Татар халык дастаны. Казан, 1994 ел.
Л. Җамалетдин. Татар халык әкиятләре. Тылсымлы әкиятләр. Казан, 1994 ел.
С. Гыйләҗетдинов. Татар халык риваятьләре һәм легендалары. Казан, 2000 ел.
Ф. Әхмәтова-Урманче. Татар эпосы. Бәетләр. Казан, 2001 ел.
М. Садри. Иртешкә сәяхәт. Әкиятләр, җырлар. Казан, 1989 ел.
И. К. Хәйруллин. Татар халык иҗаты. Сүз эчендә хикмәт бар. Казан, 1999 ел.
К. Хөснуллин. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр. Казан, 2001 ел.
Ф. Зыятдинова. Татар халык әкиятләре. Алтын балык. Казан, 1999 ел.
Н. Вәлитова. Көмеш-Сылу. Татар халык әкиятләре. Казан, 1993 ел.
Ш. К. Шәрифуллин. Сак-Сок. Татар халык иҗаты музыкальҗәүһәрләре. Казан, 1999 ел.
Сүз эчендә хикмәт бар: Татар халык иҗаты – Казан: Мәгариф, 1999.
Баязитов Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1995.
Уразман Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1992.
“Сабантуй”, “Көмеш кыңгырау”, “Татарстан яшьләре”, “Мәгърифәт” газеталары;
“Ялкын”, “Мәйдан” журналлары.

***«Сабыйга» түгәрәгенә йөрүче татар балаларының исемлеге.***

1.Алишева Алина

2.Аглиуллин Тимур

3.Сайфуллина Айсылу

4.Сайфуллина Руфина

5.Мифтиханова Ралина

7.Алиев Румир

8.Хаметшина Альбина

9.Хаметшин Данис

10.Калимуллин Динар

11.Давлетшина Чулпан

12.Файзуллина Нәзилә

13.Хайдаров Султан

***«Сабыйга» түгәрәгенә йөрүче рус балаларының исемлеге.***

1. Кудряшов Альберт

2.Басорина Дарья

3.Прокопьев Георгий

4.Андреев Константин

5.Краснова Дарья

6.Столярова Милана

7.Демидов Артур

8.Кузьмин Артем

9.Малыгин Матвей

10.Лаврентьев Сергей

11.Живов Артем